КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 37

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 953 нче карары белән расланган Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 953 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июнь, 387 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халык белән чара – Россия Федерациясе гражданнары, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләр башлангычы буенча гамәлгә ашырыла торган ачык, тыныч, һәркем катнаша ала торган, җыелыш, митинг, демонстрация, урам йөрешләре яисә пикетлар рәвешендә яки бу формаларның төрле катнашында (шул исәптән транспорт чараларын файдаланып) үткәрелә торган акция. Халык белән чара үткәрүнең максаты – фикерләрне иркле рәвештә белдерү һәм формалаштыру, илнең сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышы буенча

төрле мәсьәләләргә һәм тышкы сәясәт мәсьәләләренә карата таләпләр кую яки дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты белән сайлаучылар очрашканда сайлаучыларга үз эшчәнлеге турында хәбәр итү;»;

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Халык белән чара (сайлаучылар белән очрашканда сайлаучыларга үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү максатларында, дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тарафыннан үткәрелә торган халык белән чарадан, шулай ук, тиз торгызыла һәм җыела-сүтелә торган конструкция кулланмыйча, бер генә катнашучы тарафыннан үткәрелә торган җыелыштан һәм пикеттан башка) үткәрү турындагы хәбәрнамә язма рәвештә аны оештыручы тарафыннан халык белән чара үткәрү көненә кадәр иң күбе 15 көн алдан һәм 10 көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле органга кертелә.

Сайлаучылар белән очрашканда сайлаучыларга үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү максатларында, дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тарафыннан үткәрелә торган халык белән чара (тиз торгызыла һәм җыела-сүтелә торган конструкция кулланмыйча, бер генә катнашучы тарафыннан үткәрелә торган җыелыштан һәм пикеттан башка) турындагы хәбәрнамә халык белән чара үткәрү көненә кадәр иң күбе 10 көн алдан һәм 5 көннән дә соңга калмыйча кертелә.

Җәяүлеләр һәм транспорт чаралары хәрәкәте өчен каршылык тудыра, тиз торгызыла һәм җыела-сүтелә торган конструкция кулланып, затлар төркеме тарафыннан пикет үткәрелгәндә яисә бер генә катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пикетны үткәргәндә халык белән чара үткәрү турындагы хәбәрнамә – аны үткәрү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, әгәр дә күрсәтелгән көннәр якшәмбе һәм (яки) эш көне булмаган бәйрәм көненә (эш көне булмаган бәйрәм көннәренә) туры килсә, аны үткәрү көненә кадәр дүрт көннән дә соңга калмыйча кертелә. Әгәр дә халык белән чара үткәрү турында хәбәрнамә бирү вакыты тулысынча эш көне булмаган бәйрәм көннәренә туры килсә, хәбәрнамә эш көне булмаган бәйрәм көннәренә кадәр булган соңгы эш көнендә бирелергә мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин